| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2022 г. Казань № 768-292/тп-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташтыруга стандартлаштырылган тариф ставкаларын һәм түләү формуласын билгеләү турында» 2022 елның 18 ноябрендәге 652-216/тп-2022 номерлы карарына 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары белән расланган Электр энергиясеннән файдаланучыларның энергия кабул итү җайланмаларын, электр энергиясе җитештерү объектларын, шулай ук челтәр оешмаларыныкы һәм башка затларныкы булган электр челтәрләре хуҗалыгы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыру кагыйдәләре, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2022 елның 30 июнендәге 490/22 номерлы боерыгы белән расланган Электр челтәрләренә технологик тоташтырган өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик күрсәтмәләр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 20 декабрендәге 45-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташтыруга стандартлаштырылган тариф ставкаларын һәм түләү формуласын билгеләү турында» 2022 елның 18 ноябрендәге 652-216/тп-2022 номерлы карарына 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «8.2.1 | $C_{8.2.1}^{0,4\text{ кВ и ниже}}$ | өч фазалы турыдан-туры тоташтырыла торган электр энергиясен (егәрлеген) коммерция исәбенә алу чаралары | исәпкә алу ноктасы өчен, сум | 41 791 |
| | $C_{8.2.1}^{1–20\text{ кВ}}$ | | | 575 143»; |

8.2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «8.2.2 | $C_{8.2.2}^{0,4\text{ кВ и ниже}}$ | өч фазалы ярымчитләтеп тоташтырыла торган электр энергиясен (егәрлеген) коммерция исәбенә алу чаралары | исәпкә алу ноктасы өчен, сум | 168 325 |
| | $C_{8.2.2}^{1–20\text{ кВ}}$ | | | 330 272»; |

8.2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «8.2.3 | $C_{8.2.3}^{1–10\text{ кВ}}$ | өч фазалы читләтеп тоташтырыла торган электр энергиясен (егәрлеген) коммерция исәбенә алу чаралары | исәпкә алу ноктасы өчен, сум | 767 212[<3>] |
| | $C_{8.2.3}^{35\text{ кВ}}$ | | | 2 044 688[<3>] |
| | $C_{8.2.3}^{110\text{ кВ и выше}}$ | | | 7 273 427[<3>]». |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев